**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге советы**
**КАРАРЫ**

№ 41 16 ноябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Советының 21.01.2014 елнын 57 нче номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (21.11.2016 елнын 48 нче номерлы, 04.09.2017 елнын 66 нчы номерлы, 02.07.2018 елнын 103 нче номерлы, 12.03.2019 елнын 131-4 нче номерлы, 18.02.2020 елнын 165-23 нче номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 өлеше, 32, 33 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 30.06 2021 елдагы җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә

Уразай Авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 21.01.2014 елнын 57 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (21.11.2016 елнын 48 нче номерлы, 04.09.2017 елнын 66 нчы номерлы, 02.07.2018 елнын 103 нче номерлы, 12.03.2019 елнын 131-4 нче номерлы, 18.02.2020 елнын 165-23 нче номерлы карарлар редакциясендә)

1.1. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында

- Татарстан Республикасы, Уразай авыл җирлеге, Уразай авылы, Н.Бәдертдинов ур. адресы буенча урнашкан 16:02:190101:805, 16:02:190101:804 кадастр номерлы 670,0 һәм 803,0 кв.м. җир кишәрлекләре өчен территориаль зонаны П1 куркынычы IV-V классly җитештерү-коммуналь предприятиеләрне урнаштыру зонасыннан Ж1 индивидуаль торак зонасына үзгәртергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Советы торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шэрифуллина